# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авылында 2025 елга үзара салым кертү турында

№2 30.10.2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында узган гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, МХОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срок хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 нчы елда 700 (җиде) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Уразбахты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Шәйхетдинов